ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш), № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «шартлары турындагы карарлар,» сүзләрен «шартлары турында әлеге статьяның $3^1$ өлеше нигезендә урнаштырылырга тиешле карарлар,» сүзләренә алмаштырырга;

2) $3^1$ өлешкә «урнаштырылырга тиеш» сүзләреннән соң «, моңа «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктының 1, $1^1$, 5, 9 һәм 10 пунктчаларында каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карар керми» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 21 июнь
№ 42-ТРЗ